КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 декабрь г.Казань № 1201

2025 елда «Северные ворота» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез милек объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2019 ел, 23 апрель, 331 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2025 елда акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган «Северные ворота» акционерлык җәмгыятенә (алга таба – акционерлык җәмгыяте) 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә акционерлык җәмгыяте милкендәге «Северные ворота» индустриаль (сәнәгать) паркының капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан 2 500 000 000,0 сум күләмендә субсидия бирү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак әлеге карарның 1 пункты нигезендә субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Россия Федерациясе законнары нигезендә акционерлык җәмгыятьнең устав капиталын тиешле дәрәҗәдә

арттыруга юнәлдерелгән акционерлык җәмгыятьнең гамәлләрен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 30 декабрь, 1201 нче
карарына 1 нче кушымта

## «Северные ворота» акционерлык җәмгыяте милкендә булган, капитал салулар гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектлары

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Объектның куәте | ҮБГК буенча куәтнең үлчәү берәмлеге | Инвестицияләү юнәлеше | Заказчы исеме | Төзүче исеме | Эксплуатациягә тапшыру срогы | Объектның смета кыйммәте, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | | | | Капитал салулар күләме, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | барысы | шул исәптән өстәлгән кыйммәткә | шул исәптән проект документациясен әзерләүгә, инженерлык тикшеренүләрен үткәрүгә бүлеп бирелә торган акча | 2025 елга | 2026 елга | 2027 елга | 2028 – 2032 елларга | барысы | 2025 елга | 2026 елга | 2027 елга | 2028 – 2032 елларга |
| 1. | «Северные ворота» индустриаль паркы «Прототиплаштыру инфраструктурасы» | 76 000 | кв.м | төзелеш | «Северные ворота» АЖ | «Северные ворота» АЖ | 2028 елның феврале | 24 495 803,84 | 4 042 664,33 | 525 346,56 | 3 000 000,0 | 14 154 786,56 | 5 526 001,58 | 1 815 015,7 | 24 495 803,84 | 3 000 000,0 | 14 154 786,56 | 5 526 001,58 | 1 815 015,7 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 30 декабрь, 1201 нче
карарына 2 нче кушымта

2025 елга «Северные ворота» акционерлык җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасын бүлү

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Субсидияләр суммасы, сум (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) |
|---|---|---|
| 1. | «Северные ворота» индустриаль паркы «Прототиплаштыру инфраструктурасы» | 2 500 000 000,0 |
| Барлыгы | | 2 500 000 000,0 |

________________________________________